
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№5
Январь 2020 г.

## Сугыш кайтавазы…



**Тукта, иптәш, тукта!**
Минем яннан
Тыныч кына үтеп китмә
син!
Мин бит гади бер сын гына
түгел.
Мин - көрәшче!
Авылдашың синең,
иптәшең!

Онытма син!
Бик кыйммәткә төште
Синең бәхет безгә!
Шул хакта гел сөйләп тору
өчен
Таш сын булып, һәйкәл
булып
Кайттык бүген Сезгә!

## Моны белү кирәк!

- ♦ Бөек Ватан сугышында илебез 27 миллионнан артык кешесен югалтты.
- ♦ Һәр югалткан солдатны бер минутлык тынлык белән искә алсак, илебез 50 елга тынар иде.
- ♦ Сугыш корбаннарын хәтер парадына чыгарсак, аларның юлы 19 тәүлеккә сузылыр иде.
- ♦ kremnik.ru—хәбәрсез югалганнарны эзләүче сайт. Анда катнашучылар саны—98003
- ♦ kremnik.ru сайтына теркәлүчеләр саны — 446922

## Онытырга мөмкин түгел…

**“Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк, үлгәннән соң да үлмәслек булсын- яшәүнең бөтен мәгънәсе шунда!”**

Тоткынлык газапларын башыннан кичергән, батырлыгы дөньяны таң калдырган шагыйрь – М.Җәлил сүзләре болар.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк 40тан артык татар язучылары үзләре теләп сугышка китәләр. Тора-бара сугышка китәргә теләк белдерүче язучыларның саны тагын да арта. Фронтовик язучылар сафында Абдулла Алиш, Габдрахман Әпсәләмов, Гадел Кутуй, Сибгат Хәким, Фатих Кәрим, Ибраһим Гази, Муса Җәлил, Афзал Шамов, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Шәйхи Маннурлар бар.

Меңәрләгән шәһәрләрне җимергән, җир йөзендә гөрләп торган авылларны юкка чыгарган, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән.

Иң кызганычы - 27 миллион кешенең гомере өзелгән, күпме бала ятим, аналар тол калган Сугыш җәрәхәте, балачагы урланаган өлкәннәр йөрәгендә мәңге җуелмас эз калдырган. Бүген аларның шушы яралары әрнеп сызлый, чөнки тиздән Бөек җиңүгә 75 ел була, бу - иң яшь сугыш чоры баласына да 75 яшь була дигән сүз!

Алар бүген безнең яклауга мохтаж. Әйдәгез, онытмыйк өлкәннәребез турында!

**Рәсимә Ибраева**
“Яшь журналист” түгәрәге
җитәкчесе


## Бу санда:


| | |
|---|---|
| Ут белән шаярырга ярамый! | 2 |
| Исемнәр үзгәртелгән, юллар өзелгән… | 2 |
| Ал гыйлем… | 3 |
| Рәсәй каһарманнары көне | 3 |
| Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә 86 ел | 4 |
| Бердәмлектә – көч! | 5 |

# Исемнәр үзгәртелгән, юллар өзелгән...

**Хәтирә Мәрданшина әнисенең абыйларын эзләгәндә көтелмәгән хәлләргә юлыга. Башкаларның да шундый аңлашылмаган хәлдә калуларын күреп, ярдәм итәргә алына. Инде менә өч ел дәвамында ул йөзләгән кешенең эзенә төшкән, язмышын ачыклый алган.**

Мәрданшиннар гаиләсе Татарстанга күченеп кайтканнан соң, тумышы белән Азнакай районы, Мәлбагыш авылыннан булган 86 яшьлек әнкәйләре кызы Хәтирәгә Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган туганнарын ачыкларга кирәклеген әйтә. Менә шуннан башлана инде тынгысыз эзләнүләр. "Әни исән чакта аңа хәбәр итәсем килде, шуңа да минем вакытым чикле иде. Бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга тырыштым. "Хәтер китабы" редакциясенә дә




бардым, интернетта да утырдым. Төрле сайтларны эзләп таптым", – дип сөйли ул. Эзләнә, бер дәлилне икенчесе янына бәйли торгач, документлардагы Әхмәтшин Нәшир Мофаздал улының әнисе Хәтимәнең абыйсы Әхмәтшин Әхмәткәшиф Мофаздал улы булуын ачыклый.

Кәшиф абый үлгән Орлов өлкәсендәге язуларны дөресләр өчен дәлилләр, рәсми кәгазьләр кирәк булып чыга. "Хәтер китабы" редакциясе хезмәткәре Валентина Липатинкова Хәтирәнең бөтен кәгазьләрен җыеп, Мәскәүгә җибәрә. Абыйсы җирләнгән Орлов өлкәсеннән хат килә. Анда исә сугышчының исемен рәсми рәвештә теркәргә дигән карарга шәһәр хәрби комиссариаты җитәкчесе кул куйган. Әнә шулай Курск сугышында катнашып һәлак булган Кәшиф абыйның күмелгән урыны ачыклана һәм теркәлә. Озакламый алар шул якларга барып та кайталар. Орлов өлкәсендә һәлак булган 175 кеше генә ачыкланган булса, Хәтирә ханымның ярдәме белән аларның саны меңгә җитә.

**Рәсимә Муллаянова**
www.vatantat.ru

# Ут белән шаярырга ярамый!

***Бүгенге көндә янгын килеп чыгу очраклары еш күзәтелә. Шуны күздә тотып, Арчаның 2 нче номерлы урта гомуми белем мәктәбендә "Ут белән шаярырга ярамый!" дигән темага янгын куркынычсызлыгы буенча класстан тыш чара булды.***

Әлеге чарада озынайтылган көн төркеменә йөрүче укучылар катнашты. Укучылар "Ялкын" һәм "Күмер" командаларына бүленде. Аларны кызыклы бәйгеләр көтә иде: укучылар янгын сүндерүчеләр буларак "Кем тизрәк киенә", янгын чыккан очракта телефоннан тиз генә хәбәр бирергә, янгын темасына рәсем ясарга, гадәттән тыш хәл вакытында үзеңне ничек тотарга, башкаларга ничек ярдәм итәргә кебек кызыклы ярышларда катнаштылар, табышмакларга җаваплар таптылар.

Бәйгедә укучылар янгын куркынычсызлыгы турында шигырьләр дә сөйләп үздылар. Янгын вакытында үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында видеро-лик һәм мультфильмнар карап ял иттеләр.



Укучыларнын тырышлыгы белән рәсем күргәзмәсе дә оештырылган иде. Җюри әгъзасы Динә Мансур кызы гадел хөкем итте, чөнки бар да тырышты, берәүне дә үпкәләтәсе килми бит.

Ярыш дуслык җиңүе белән тәмамланды. Һәр команданы котлап грамоталар бирелде. Балалар бик шатландылар. Ә кичәнең иң зур кунагы – Арча һәм Әтнә районнары буенча янгын күзәтчелеге бүлеге дәүләт инспекторы Сотов Антон Юрий улы иде. Ул безгә матур , файдалы чара уздырган өчен рәхмәтен белдерде. Ут белән сак булырга өндәде, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча киңәшләрен бирде.Укучыларны Арча һәм Әтнә районнары күзәтчелеге бүлегенә экскурсиягә чакырды. Класстан тыш чара файдалы һәм күңелле булды.

**Раушания Бакиева**
**Айсылу Аглиуллина**
**Диләрә Зайнетдинова**

## Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул...

*Габдрәхим Утыз Имәни*

**2019-2020 уку елында Бөтенрәсәй олимпиадасының муниципаль этабында җиңү яулаган укучыларыбыз**

| | |
|---|---|
| Астрономия | Гатауллина Ляйсан |
| Русский язык | Иконникова Ляйсан |
| | Шарипов Рузаль |
| | Степанов Данил |
| Литература | Степанов Данил |
| | Ризванова Эльвина |
| | Шарипов Рузаль |
| | Сабирова Исламия |
| Татарский язык | Шарипов Рузаль |
| | Фахрутдинова Азалия |
| | Давлетова Алия |
| | Хайрутдинова Дина |
| | Демухаметов Амин |
| | Спиридонова Ангелина |
| | Низамова Ралия |
| | Аюпова Алина |
| | Никитина Эльзана |
| | Асхабова Ясмин |
| | Уваева Оксана |
| | Спиридонова Анна |
| | Степанов Данил |
| | Мубаракшин Дамир |
| | Аглиева Адиля |
| Татарская литература | Низамова Ралия |
| | Хабирова Алия |
| | Ахметханова Эльза |
| | Забирова Зулейха |
| | Ахмадуллина Алсу |
| Английский язык | Газизов Данил |
| | Усманов Марсель |
| | Ярullина Дина |
| Биология | Фролов Дмитрий |
| История Татарстана | Степанов Данил |
| Обществознание | Степанов Данил |
| | Низамова Ралия |
| | Гатауллина Ляйсан |
| Право | Степанов Данил |
| | Гатауллина Ляйсан |
| | Валишин Азамат, |
| ОБЖ | Ахметханова Азалия |
| | Галимов Ильназ |
| | Ханафиев Данил |
| | Галимова Диана |
| | Никитина Эльзана |
| Физическая культура | Мингазова Илюза |
| | Шагимуллина Аделина |
| | Гарифуллина Адиля |
| Технология | Ахметгалиева Азалия |
| | Хайрутдинова Дина |
| | Миннебаева Алия |
| | Мухаметшина Азалия |
| | Насифуллин Амир |
| | Фаттахов Расим |

## Яшь армиячеләр катнашында узган Рәсәй каһарманнары көненнән фоторепортаж









# Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә 86 ел

***Советлар Союзы Герое дигән иң югары дәрәҗәле исем моннан 86 ел элек-СССР Үзәк Башкарма Комететының 1934 ел 16нчы апрель Карары нигезендә булдырыла.***

Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары өчен, Арча районыннан биш батырга әлеге мәртәбәле исем бирелә:

**Салихов Гатаулла Салих улы** 1924 елның 1гыйнварында Арча районы Түбән Оры авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлый, колхозда эшли, 1942 елда Совет армиясенә китә.

1943 елның февраленнән хәрәкәттәге армиядә 518 нчы укчы полк отделение командиры сержант Салихов 1943 елның 12 июленнән 3 сентябренә кадәр Большой Малиновец һәм Сетуха авыллары янында сугышта зур батырлыклар күрсәткән. Снайпер мылтыгы һәм пулеметтан ут ачып 40тан артык дошманны юк иткән. Кискен сугыш барышында башта взвод командирын алыштырып, сугышчыларны штыклы һөҗүмгә күтәреп дошманга ташланган. 1943 елның 27 августында аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

**Сафин Накыйп Сафа улы** 1921 елда Мирҗәм авылында туа. Милләте татар. Иркутск өлкәсендә



тимер юлда эшләгән. 1940 елдан Совер Армиясендә. 1941 елда сугышта.

19 аерым моторлаштырылган понтон–күпер салу батальонында отделение командиры Сержант Сафинага әйләнә. 1943 елның 28 сентябрендә Соломино авылы янында Днепр елгасы ярга понтон белән беренче төркем сугышчыларны чыгарып җибәрәләр. 1943 елның 20 декабрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Сугыштан соң хәрби – инженерлык училищесында укыган. 1946 елдан лейтинант Сафин запаста. Туган җиренә кайта. 1051 елда Казанда республика партия мәктәбен бетергән. Соңнан ул совхозда директор булып эшләгән. Ике Ленин, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

1987 ел 22 майда вафат. Казанда җирләнә.

**Сафиуллин Гани Биккенә улы** 1905 елның 1 нче июлендә Иске Кишет авылында туа. Җидееллык сыйныфны тәмамлый. Казахстан ССР ның Семипалат шәһәрендә өяз комсомол комитеты инструкторы булып эшләгән. 1927 елдан Совет Армиясе сафларында. 1928 елдан запастагы взвод командирлары мәктәбен, 1931 елда Чик сакчылары югары училищесын, 1941 елда М.В. Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлаган. Полк белен җитәкчелек иткән. 1941 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында.

Дала фронты составындагы 7 нче гвардия армиясенә кергән, генерал-майор Сафиуллин җитәкчелек иткән 25 нче укчы корпус 1943 елның 25 сентябренә каршы төндә –Бородаевка һәм Домоткань авыллары тирәсендә (Днепропетровск өлкәсенең Югары Днепров районы) Днепрны кичкән. Полк һәм дивизия артиллерия көчләре белән дошманның күпсанлы контрһөҗүмнәрен кире кайтарып, 5 көнлек сугышта фронт буенча плацдармны озынлыгын 25 чакрымга, иңен 15 чакрымга киңәйткән һәм шунда урнашкан. 1943 елның 26 октябрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Казанда яшәгән һәм эшләгән. Ике Ленин , өч Кызыл Байрак, ике II дәрәҗә Суворов, ике II дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләре белән бүләкләнә. 1973 елның 13 октябрендә вафат була. Казанның Арча кыры зиратында күмелгән. Авылында музее бар. Арча станциясендәге бер урам аның исемен йөртә.

**Соколов Леонид Михаил улы** 1908 елның 23 апрелендә Бимәр авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Рус. Казанда 9 нчы сыйнфыны тәмамлый. Аэроклубта очучы-инструктор, бераздан звено командиры булып эшләгән.

Хәрәкәттәге армиягә 1942 елның декабрендә алына.

1 нче Украина фронты составындагы 2 нче һава армиясенә караган 2 нче штурм авиациясе корпусына кергән 11 нче гвардия истрибительләр авиациясе дивизиясенең 107 нче гвардия истрибительләр авиациясе полкы эскадрилья командиры гвардия майоры Соколов 1945 елның маена кадәр 230 сугышчан очыш ясаган. 62 һава сугышында дошманның 17 самолетын, группа белән 6 самолетын бәреп төшергән. 1945 елның 27 июлендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Сугыштан соң Хәрби һава көчләрендә хезмәтен дәвам иткән. Смоленскта яшәгән һәм эшләгән. Ленин, өч кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз орденлары, медальләре бар.

1981 елның 12 маенда вафат.

**Ежков Валентин Федор улы** 1922 нче елның 27 маенда Арча бистәсендә туа. Урта белемле. Харьков трактор заводында эшләгән. 1942 елның июленнән сугышта.

Көньяк фронт составындагы 2 нче гвардия армиясенең 3 нче укчы полкының дивизиясенә караган 13 нче гвардия укчы полкының танкка каршы атучы мылтыкчылар ротасы командиры гвардия өлкән лейтинанты Ежков 1943 елның 19 августында Степановка авылы (Донецк өлкәсенең Шахтер районы) янында барган сугышларда батырлык курсәткән. Ул җитәкләгән рота, дошманның өч һөҗүмен кире кайтарып, аның 12 танкын юк итә. Шул сугышта һәлак була. Советлар Союзы Герое исеме 1944 елның 19 нчы мартында үлгәннән соң бирелә. Ленин ордены белән бүләкләнә. Степановка авылында җирләнә. Бүген Арчабызның бер урамы, мәктәбе, чишмәсе аның исемен йөртә.

**Рүзәл Шәрипов,** Х сыйныф

**УКУЧЫСЫ**

# Бердәмлектә – көч!



Мәктәбебездә 2017 елда оешкан “Бердәмлек” укучылар үзидарәсенең президенты, министрлары һәм аларның урынбасарлары бар. Алар һәрберсе беркетелгән эшләрен башкаралар. Әйтик, мәгариф министры һәр классның өлгереш табелен барлый, экология министры тирә-яктагы чисталыкны саклау бурычын куя, моның өчен кызыклы акцияләр уйлап табыла, мәсәлән, макулатура, кулланылган батарей җыюны оештыра.

Юл йөрү идарәсе министры башлангыч сыйныфы укучылары арасында юл йөрү фаҗигаләрен бетерү юнәлешендә эш алып бара. 2018—2019 уку елында «Иң яхшы юл йөрү идарәсе» бәйгесендә җиңеп, кубокка ия булдык.




Әле күптән түгел генә “Яхшылык югалмый” проектында безнең мәктәпнең “Поколение ТимуроNext” волонтерлар төркеме 200 мең грантка ия булды.

Эшчәнлегебезнең нәтиҗәсен без ай саен класслар арасында оештырылган рейтингта чагылдырып, иң-иңнәрне күчмә кубок белән бүләклибез. Эшебезне без төрле социаль челтәрләрдән кала, “Мәктәп пульсы” газетасында чагылдырып барабыз. Ул 2016 елдан бирле чыгып килә, аны «Яшь журналистлар” түгәрәге уку-чылары үз көчләре белән чыгара.

Мәктәптә «Яшь армиячеләр» отряды актив эшли. Укучылар районның социаль эшләрендә, хәрби спорт уеннарында, ярышларда актив катнашалар. Отряд белән «Яшь армиячеләр» министры 9нчы сыйныф укучысы Самвел Алврцян җитәкчелек итә.



“Бердәмлектә – көч” девизы астында без барыбыз да бердәм команда булып эшлибез.


**Динә Ибраһимова**,
педагог-оештыручы







*“Поколение ТимуроNext” волонтерлары*





# Кешелек дөньясы  онытырга тиеш түгел!

***Җәлилче Әмир абый Үтәшев сугышка хәтле Арчаның Интернационал урамы 35 нче йортта яши. Хатыны – укытучы Рәйсә Йосыф кызы, ә кызлары — Әлфия. Әмир абый Үтәшев ул елларда райпотребсоюзда баш бухгалтер булып эшли.***

Бөек Ватан сугышы башлангач, аны армиягә алалар. Алабугада политруклар әзерләүче курсларны тәмамлагач, өлкән лейтинант Үтәшев, батальон комиссары буларак, беренче сугышчан чыныгуны 1942 елның июне азагында Курск янында ала. Хәлиткеч көрәшләрнең берсендә фашист танклары белән “дуэль” вакытында ул, ике аягы да авыр яраланып, аңын югалта. Аңсыз хәлдә берничә тәүлек бомба чокырында ята. Шул хәлдә әсирлеккә эләгә. 1942 елның 6 июлендә аның өчен газаплы тоткын тормышы башлана...

1943 елның маенда Ә.Үтәшевне Польшаның Едлинодагы хәрби әсирләр лагеренә – “Идел-Урал” легионына китерәләр. Бирედә ул Рәхим Саттар ярдәмендә Муса Җәлил белән таныша. Яшерен оешма әгъзасы булып китә. Муса Җәлил  Әмиргә әйтә: “Синең һәм минем төп максат – үзебезнең ватандашларны партизаннар ягына алып чыгып, фашистларга каршы көрәшү! Мин сиңа ышанам!”

“Идел-Урал”легионының ике батальонын Беларусь партизаннарына озаткач, М.Җәлил һәм җәлилчеләрне кулга алалар. Бу вакыйгадан соң, Көнчыгыш фронтка әзерләгән өченче татар легионын Гитлер Франицягә җибәрә. “Идел-Урал” легионының бу өченче батальонында писарь Әмир Үтәшев тиз арада француз партизаннары белән элемтәгә керә һәм сакчы немецларны коралсызландыра.

Арчадан сугышка киткән Әмир абый ике меңгә якын легионерны һәм Габбас Шарипов белән Нигъмәт Терегулов белән берлектә дөньяны тетрәткән “Моабит дәфтәре”нең саклап туган илебезгә кайтарып, чын егетлек күрсәтә.

Әмир Үтәшев сугыш беткәч, 1945 елның 1 сентябрендә кулга алына. Харби трибунал аны “әсирлеккә төшеп ватанга хыянәт иткән өчен”, дип атарга хөкем итә. Бераздан бу карар 25 елга төрмә-каторга белән алыштырыла.

Гаделлек, дөреслек тантана итсен өчен курку белмәс Әмир агага совет төрмәләрендә дә бик озак көрәшергә



туры килә. Ниһаять, 1990 елның 5 маенда «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында актив катнашучыларны 1 нче дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләү турында” Советлар Союзы Президенты Указы нигезендә Әмир ага да акланып бүләкләнә.

Соңгы елларны Казанның Гадел Кутуй урамында Рәйсә апа белән  кызлары Әлфияне дә энисе кебек укытучы итеп үстерәләр.  Ә оныклары Кадрияне яшь шагыйрә итеп тәрбиялиләр. Җәлилче  Әмир Үтәшев 1996 елның 6 февралендә (77 нче яшендә) инфаркт-инсульттан вафат була. Ул Казанның Яңа бистәдәге мөселман зиратына җирләнә. Совет каһарманының кабере өстенә мәрмәр таш куелган.

**Азат Исмәгыйлев,** VIII сыйныф

Раушания Бакиева

Азат Исмәгыйлев

*“Арча хәбәрләре”нең 41,42 нче саннарыннан*


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов

***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов

***Корректор*** Ислам Габдрахманов

***Редколлегия*** Алия Хабирова

Азат Исмагилов

***Адрес:*** ул. Мост овая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2